**МИНПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИИ**
**Федеральное государственное образовательное учреждение высшего образования**
**«Башкирский государственный педагогический университет им. М.Акмуллы»**
**(ФГБОУ ВО «БГПУ им. М.Акмуллы»)**

Утверждено на заседании
Ученого совета БГПУ им.М.Акмуллы
№6 от 19 января 2026 г.
ректор
_________________________ С.Т. Сагитов

# ПРОГРАММА
## ВСТУПИТЕЛЬНОГО ИСПЫТАНИЯ ТВОРЧЕСКОЙ И (ИЛИ) ПРОФЕССИОНАЛЬНОЙ НАПРАВЛЕННОСТИ

## ПРОФЕССИОНАЛЬНОЕ ИСПЫТАНИЕ РОДНОЙ (ТАТАРСКИЙ) ЯЗЫК И ЛИТЕРАТУРА

Программа вступительных испытаний разработана на основе Федеральных государственных образовательных стандартов среднего общего и среднего профессионального образования

Уфа

## 1. Особенности проведения вступительного испытания

На выполнение комплексного экзамена по направленности (профилю) «Татарский язык и литература» дается 60 минут. Работа включает в себя 25 заданий (тестовые задания закрытого типа). Оценивается по 100-балльной шкале. Баллы выставляются за полностью верно выполненное задание.

Поступающие с ограниченными возможностями здоровья имеют право на увеличение времени (но не более чем на 1,5 часа).

**Вступительное испытание проводится с использованием дистанционных технологий** (инструкция прохождения вступительного испытания и получения логина и пароля)**:**

Для прохождения вступительных испытаний поступающий должен иметь персональный адрес электронной почты, на который ему будет направлена информация для доступа к заданиям.

Вступительные испытания проходят в соответствии с утвержденным расписанием и процедурой идентификации личности.

Вступительные испытания могут проводиться в следующих форматах:

- с применением функционала электронной информационной системы (единая информационная система управления учебным процессом «Tandem University» (далее – «личный кабинет абитуриента»);

- в формате видеоконференцсвязи под визуальным контролем посредством системы видеосвязи (посредством платформы для видеоконференции).

Перечень требований к программно-техническому оснащению рабочего места поступающего для прохождения вступительных испытаний:

А) Компьютер, отвечающий следующим минимальным требованиям:

- тактовая частота процессора - не менее 1 ГГц;
- не менее 512 Мб оперативной памяти;
- не менее 32 Мб видеопамяти;
- не менее 5 Гб свободного места на жёстком диске;
- веб-камера с разрешением не менее 2 Мпикс;
- микрофон;
- колонки/наушники;

Б) Возможно применение планшета со схожими характеристиками при условии его стационарного размещения на время проведения испытания.

Требование к телекоммуникационной сети: возможность доступа в сеть Интернет на скорости не ниже 1 Мбит/сек. Абитуриенты самостоятельно обеспечивают и оплачивают доступ к телекоммуникационным каналам передачи данных в сетях общего пользования (Интернет).

Программное обеспечение:

- установленные драйверы для всех перечисленных выше периферийных устройств.
- текстовый редактор.

- графический просмотрщик изображений в форматах jpg, png, gif.

Абитуриент не имеет права во время вступительных испытаний:
- привлекать помощь третьих лиц;
- предоставлять доступ к компьютеру посторонним лицам;
- использовать учебную и справочную литературу, конспекты и иную вспомогательную литературу, не предусмотренную программой вступительных испытаний;
- искать информацию в сети Интернет;
- открывать дополнительные окна в браузере;
- использовать любые мобильные и компьютерные устройства, кроме персонального компьютера, на котором осуществляется прохождение вступительного испытания.

## 2. ПЕРЕЧЕНЬ РАЗДЕЛОВ ДЛЯ ПОДГОТОВКИ ПОСТУПАЮЩИХ К СДАЧЕ ВСТУПИТЕЛЬНОГО ИСПЫТАНИЯ

## РАЗДЕЛ 1. ФОНЕТИКА. ГРАФИКА. ЛЕКСИКОЛОГИЯ

### 1.1. Татар теле турында гомуми мәгълүмат

Тел – иҗтимагый күренеш. Тел үсеше турында гомуми мәгълүмат. Татар әдәби теле нормаларының борынгыдан ук үсеп килүе. Милли татар әдәби теле формалашу этаплары. Төрки халыклар өчен гомуми булган борынгы төрки әдәби тел (V-X йөзләр) һәм аның үрнәкләре. Төрки халыклар өчен гомуми булган иске төрки тел (X-XV йөзләр) һәм аның үрнәкләре. Иске татар әдәби теле (XV-XIX йөзләр) һәм аның үрнәкләре. Хәзерге (милли) татар әдәби теленең барлыкка килүе, аның үсешендә төп үзенчәлекләр.

Ике теллелек һәм сөйләм культурасы. Телләрнең үзара тәэсире. Төрки, фин-угор, славян телләре турында төшенчә. Бу телләрнең үзара тәэсир итешүләре тарихы. Төрки телләр арасында татар теленең урыны.

Диалект турында төшенчә. Татар теленең төп диалектлары: урта диалект, мишәр диалекты (көнбатыш диалект), себер татарлары теле (көнчыгыш диалект). Аларның төп үзенчәлекләре, тамырлары: болгар-татар, мишәр-татар, себер-татары. Башкортстанда таралган татар сөйләшләре, аларның төп үзенчәлекләре.

Хәзерге татар әдәби теленең үсеш үзенчәлекләре. Татар теле галимнәре турында кыскача белешмә. Башкортстанда татар теле белеменең үсеше.

Тел гыйлеменең әһәмияте. Тел гыйлеме һәм аның тармаклары. Тел гыйлеменең башка фәннәр белән бәйләнеше.

### 1.2. Фонетика

**Фонетика** турында төшенчә. Сөйләм органнары. Аваз һәм фонема турында төшенчә. Авазларның ясалышы. Сузык һәм тартык авазлар, алар арасында аерма.

**Сузык авазлар**. Аларның саны һәм составы. Алгы рәт (нечкә) һәм арткы рәт (калын) сузыклар.

Иренләшкән һәм иренләшмәгән сузыклар. Алынма сузыклар. **[о]** һәм **[о]**, **[е]** һәм **[е]**, **[ы]** һәм **[ы]** авазларының әйтелеше.

**Сингармонизм** законы, аның ике төре: рәт гармониясе һәм ирен гармониясе. Сингармонизм законы сакланмаган очраклар.

Сузыкларның кыскаруы (редукция). Өстәмә аваз кушылуы (протеза, эпентеза). Элизия күренеше.

**Дифтонглар** турында төшенчә. Татар телендә дифтонглар.

**Тартык авазлар**. Аларның саны һәм составы. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. Тел арты тартыклары һәм увуляр тартыклар.

Ирен-ирен һәм ирен-теш тартыклары. **[к]**, **[г]** һәм **[къ]**,**[гъ]** тартыклары.

[**һ**] һәм [**х**] тартыклары. [**н**] һәм [**ң**] тартыклары.

[**W**] һәм [**в**] тартыклары. [**'**] – һәмзә тартыгы. Сөйләмдә тартык авазларның үзгәреше: охшашлану (ассимиляция), охшашсызлану (диссимиляция), җайлашу (аккомадация). Тартык авазларның чиратлашуы.

**Иҗек** турында төшенчә. Татар телендә иҗек калыплары. Ачык һәм ябык иҗекләр.

**Басым** турында төшенчә. Басым төрләре: сүз (иҗек) басымы, логик басым, синтагма басымы. Алынма сүзләрдә басым.

**Интонация** турында төшенчә. Интонациянең өлешләре: фраза басымы, логик басым, тойгы басымы, сөйләм көе. Интонациянең төрләре.

**Графика** һәм **орфография** турында төшенчә. Аваз һәм хәреф.

Авазларны язуда күрсәтү. Алфавит.

Сузык аваз хәрефләре. **О, о, ы, э, е** хәрефләренең дөрес язылышы. **Е, е, ю, я** хәрефләренең дөрес язылышы.

Тартык аваз хәрефләре. **Ч, ж, в** хәрефләренең дөрес язылышы. [**къ**] һәм [**гъ**] авазларының язуда бирелеше.

[**Җ**] һәм [**й**], [**х**] һәм [**һ**], [**н**] һәм [**н**], [**'**] авазларын белдерүче хәрефләрнең дөрес язылышы.

Сүзләрне юлдан юлга күчерү.

Татар орфографиясенең принциплары. Фонетик принцип. Тарихи-традицион принцип. График принцип. Дифференцациялэнгэн принцип.

**Татар язуның кыскача тарихы**. Рун язуы (VII йөз) турында белешмә. Гарәп язуның керүе турында белешмә. Гарәп язуының татарларда кулланылуы тарихы (922-1927 еллар).

Татар язуын латин графикасына күчерү һәм 1922-1939 елларда аны куллану. Латин графикасының татар теле өчен уңай һәм кимчелекле яклары.

Кириллицага нигезләнгән рус графикасына күчү (1939 ел). Рус графикасын татар телендә куллануның уңай һәм кимчелекле яклары.

Кириллицада татар теленең үзенчәлекле авазларын бирү.

1997 елда татар алфавитына үзгәрешләр кертү өчен омтылышлар.

1997 елда татар алфавитында хәрефләр бирелү тәртибен үзгәртү.

XX гасыр азагы – XXI гасыр башында татар язуын латин графикасына күчерү өчен галәми тырышлыклар,бу юлда сәяси каршылыклар.

**Орфоэпия** турында төшенчә. Татар орфоэпиясенең төп кагыйдәләре.

Орфоэпик кагыйдәләр бозылуның төп сәбәпләре.

**Транскрипция** турында төшенчә. Сүзгә фонетик анализ ясау.

**1.3. Лексика**

**Татар теленең чыгышы ягыннан сүзлек составы.** Гомумтөрки сүзләр. Гарәп, фарсы, рус телләреннән һәм рус теле аша башка телләрдән алынган сүзләр. Алынма сүзләрнең татар телендә үзләштерелеше.

**Татар теленең кулланылышы өлкәсе ягыннан сүзлек составы.**

Гомумхалык сүзләре. Әдәби тел сүзләре. Диалекталь сүзләр (диалектизмнар).

Профессиональ сүзләр (профессионализмнар). Атамалар (терминнар).

**Татар теленең кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан сүзлек составы.**

Искергән сүзләр (тарихи сүзләр һәм архаизмнар). Яңа сүзләр (неологизмнар). **Ономастика** фәне турында төшенчә. Аның тармакларына аңлатма бирү (топонимика, зоонимика, оронимика, антропонимика, гидронимика, космонимика һ.б.).

**Лексикография** турында төшенчә. Сүзлекләрнең төрләре. Татар теленең сүзлекләре һәм алардан файдалану. Сүзлекләрнең әһәмияте.

**1.4. Сүз ясалышы**

**Сүз ясалышы** турында төшенчә. **Сүз төзелеше**. Сүзнең мәгънәле кисәкләре. Тамыр һәм кушымча. Сүз ясагыч, мөнәсәбәт белдерүче һәм бәйләгеч кушымчалар. Аларны сүзгә ялгау тәртибе. Тамыр һәм нигез. Сүз нигезенең төрләре: тамыр нигез, ясалма нигез, кушма нигез.

**Сүз ясалышы**. Сүз ясалышы ысуллары. Сүзләргә сүз ясагыч кушымчалар ялгап, сүз ясалу.

Сүзләрне кушу (кушма сүзләр, парлы сүзләр, тезмә сүзләр), аларның дәрес язылышы. Сүзләрнең аваз составын үзгәртү.

Сүзләрнең мәгънәсен үзгәртү. Сүзләрне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү. Сүзләрне кыскарту.

Сүз төзелешен тикшерү тәртибе.

## РАЗДЕЛ 2. МОРФОЛОГИЯ

**Морфология** турында төшенчә. Сүз төркемнәре турында төшенчә.

Татар телендә сүз төркемнәре.

**Исем.** Сүз төркеме буларак исем. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр.

Исемнәрнең килеш белән төрләнеше. Исемнәрнең тартым белән төрләнеше.

Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше.

Тартым һәм килеш кушымчаларын куллануда стилистик төрлелек. Исемнәрнең ясалышы. Ясалышы ягыннан исемнәрнең төрләре: тамыр исем, ясалма исем, кушма исем, саф кушма исем, парлы исем, тезмә исем, кыскартылма исемнәр. Исемнәрнең морфологик яктан тикшерү тәртибе.

**Фигыль**. Фигыль турында төшенчә. Фигыльнең башлангыч формасы һәм барлык-юклык төре. Юклык төрендәге фигыльләрдә басым. Фигыльнең зат-сан белән төрләнеше. Фигыль юнәлешләре. Фигыль төркемчәләре турында гомуми төшенчә.

**Затланышлы фигыль формалары.**

**Боерык фигыль.** Аның мәгънәсе, зат-сан белән төрләнеше. Боерык фигыльдә басым.

**Хикәя фигыль.** Хәзерге заман хикәя фигыль. Аның мәгънәсе, ясалышы, зат-сан белән төрләнеше, дөрес язылышы.

Үткән заман хикәя фигыль. Аның формалары, аларның ясалышы һәм зат-сан белән төрләнеше. Киләчәк заман хикәя фигыль. Аның формалары, аларның ясалышы һәм зат-сан белән төрләнеше. Хикәя фигыльләрнең җөмләдә кулланылышы.

**Шарт фигыль.** Аның мәгънәсе, заман формалары, җөмләдә кулланышы.

**Затланышсыз фигыль формалары.**

**Сыйфат фигыль.** Аның мәгънәсе, заман формалары, җөмләдә кулланылышы.

**Хәл фигыль.** Аның мәгънәсе, ясалышы ягыннан төрләре, язылышы, җөмләдә кулланылышы.

**Исем фигыль.** Аның мәгънәсе, ясалышы, исем фигыльнең исемгә әйләнү очраклары, җөмләдә кулланылышы.

**Инфинитив.** Аның мәгънәсе, ясалышы, дөрес язылышы, җөмләдә кулланылышы.

**Ярдәмче фигыльләр** һәм аларның кулланылышы. Мөстәкыйль фигыльләрнең ярдәмче фигыльләр ролендә йөрүе.

Фигыльләрнең ясалышы ягыннан төрләре. Фигыльләрне морфологик яктан тикшерү тәртибе.

**Сыйфат.** Сыйфат турында төшенчә. Аның грамматик, морфологик һәм синтаксик билгеләре.

Сыйфат дәрәҗәләре. Сыйфатның ясалышы һәм язылышы. Сыйфат ясагыч кушымчалар. Синоним һәм антоним сыйфатлар.

Сыйфатларның исемләшүе. Сыйфатларның җөмләдә кулланылышы.

Сыйфатларны морфологик яктан тикшерү тәртибе.

**Сан.** Сан турында төшенчә. Сан төркемчәләре (төп сан, тәртип саны, бүлем саны, җыю саны, өлеш саны), аларның мәгънәләре һәм җөмләдә кулланылышы. Ясалышы ягыннан сан төрләре һәм аларның дөрес язылышы.

Гарәп һәм рим цифрларының татар телендә дөрес язылышы.

Саннарны морфологик яктан тикшерү тәртибе.

**Рәвеш.** Рәвеш турында төшенчә. Аларның җөмләдә кулланылышы. Рәвеш төркемчәләре: саф рәвешләр, охшату-чагыштыры рәвешләре, күләм-чама рәвешләре, вакыт рәвешләре, урын рәвешләре, сәбәп-максат рәвешләре. Рәвешләрнең ясалыш ягыннан төрләре, дөрес язылышы.

Рәвешләрне морфологик яктан тикшерү тәртибе.

**Алмашлык**. Алмашлык турында гомуми төшенчә. Зат алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнеше. Күрсәтү алмашлыклары, аларның килеш белән төрләнеше. Тартым алмашлыклары.

Сорау алмашлыклары. Билгеләү алмашлыклары. Билгесезлек алмашлыклары. Юклык алмашлыклары.

Алмашлыкларның дөрес язылышы. Алмашлыкларны морфологик яктан тикшерү тәртибе.

**Бәйлек.** Бәйлек турында гомуми төшенчә. Бәйлекләрнең төркемчәләре Бәйлек сүзләр.

Бәйлекләрне морфологик яктан тикшерү тәртибе.

**Теркәгеч.** Теркәгечләрнең төркемчәләре (тезүче теркәгечләр, ияртүче теркәгечләр). Теркәгечләрнең дөрес язылышы.

Теркәгечләрне морфологик яктан тикшерү тәртибе.

**Кисәкчә.** Кисәкчә турында гомуми төшенчә. Кисәкчәләрнең төркемчәләре. Кисәкчәләрнең дөрес язылышы.

Кисәкчәләрне морфологик яктан тикшерү тәртибе. **Хәбәрлек сүзләр**. Хәбәрлек сүзләр турында гомуми төшенчә. **Ымлыклар** һәм **аваз ияртемнәре**. Ымлыклар турында гомуми төшенчә. Аваз ияртемнәре турында гомуми төшенчә. Ымлыклар һәм аваз ияртемнәрен дөрес язу.

## РАЗДЕЛ 3. СИНТАКСИС

**Синтаксис** турында төшенчә. Синтаксик берәмлекләр. Сүзләр арасында ияртүле һәм тезүле бәйләнеш. Бәйләүче чаралар, аларның төп үзенчәлекләре.

**Сүзтезмә**. Сүзтезмә турында төшенчә. Сүзтезмәнең төзелеше.

**Җөмлә.** Җөмлә турында төшенчә. Җөмләнең төрләре.

**Әйтү максаты ягыннан җөмлә төрләре** (хикәя, сорау, боеру җөмләләр). Тойгылы җөмләләр. Җөмләләрне дөрес интонация белән уку, тыныш билгеләрен дөрес кую. Тойгылы җөмләләрне башка җөмләләрдән аеру, алардан тиешенчә файдалану.

**Ике составлы җөмләләр.** Ике составлы җөмләлр турында гомуми төшенчә. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр.

**Җөмләнең баш кисәкләре.** Ия һәм аның белдерелүе. Хәбәр һәм аның белдерелүе. Ия белән хәбәрнең җөмләдәге урыннары. Ия белән хәбәр арасында сызык кую очраклары. Ия белән хәбәр арасында дөрес интонацияне саклау, сөйләмдә ия белән хәбәрнең ярашмау күренеше.

**Җөмләнең иярчен кисәкләре.** Иярчен кисәкләр турында гомуми төшенчә.

**Аергыч** турында гомуми төшенчә. Аергычның аерылмыш белән бәйләнеше.

**Тәмамлык** турында гомуми төшенчә. Туры һәм кыек тәмамлыклар. **Аныклагыч** турында гомуми төшенчә. Аныклагычлар янында тыныш билгеләре.

**Хәл** һәм аның төрләре турында гомуми төшенчә. Урын хәле. Вакыт хәле. Сәбәп хәле. Максат хәле. Рәвеш хәле. Күләм хәле. Шарт хәле. Кире хәл.

**Җөмләнең модаль кисәкләре.** Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләре. Кереш сүзләр һәм кереш җөмләләр. Алар янында тыныш билгеләре. Эндәш һәм кереш сүзләрне дөрес интонация белән уку.

**Җөмләдә сүз тәртибе.** Җөмләдә сүз тәртибе турында гомуми төшенчә.

Җөмләдә сүзләрнең туры һәм кире тәртибе. Логик басым.

**Җөмләнең аерымланган кисәкләре.** Җөмләнең аерымланган кисәкләре турында гомуми төшенчә. Хәлләрнең аерымлануы. Аерымланган хәлләр янында тыныш билгеләре. Аныклагычларның аерымлануы. Җөмләдә аерымланган хәл һәм аныклагычларның чикләрен билгели алу, аларны дөрес укый (әйтә) алу, аларга бөйле тыныш билгеләрен кую.

**Җөмләнең тиңдәш кисәкләре.** Тиңдәш кисәкләр турында төшенчә. Тиңдәш кисәкләр янында бәйләүче чаралар һәм тыныш билгеләре. Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр, алар янында тыныш билгеләре. Тиңдәш кисәкләрне тиешле интонация белән уку.

**Тулы һәм ким җөмләләр.** Тулы һәм ким җөмләләр турында гомуми төшенчә. Сөйләмдә, бигрәк тә аның диалог төрендә, ким җөмләләрнең кулланышы.

**Бер составлы җөмләләр.** Бер составлы җөмләләр турында гомуми төшенчә. Бер составлы фигыль җөмлә. Бер составлы исем җөмлә. Бер составлы җөмләләрне сөйләмдә урынлы куллану.

Җөмләнең төрле урыннарында килгән ымлыклар белән аваз ияртемнәре янында тыныш билгеләре, аларны дөрес интонация белән уку.

**Туры һәм кыек сөйләм.** Туры һәм кыек сөйләм турында гомуми мәгълүмат. Диалог һәм аның төрләре, язылышы, тыныш билгеләре. Туры сөйләм янында тыныш билгеләре. Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндерелү.

Гади җөмләләргә анализ ясау тәртибе.

**Кушма җөмлә.** Кушма җөмлә турында гомуми төшенчә. Аның төрләре.

**Тезмә кушма җөмләләр.** Теркәгечле тезмә кушма җөмләләр. Теркәгечсез тезмә кушма җөмләләр. Тезмә кушма җөмлә эчендә тыныш билгеләре.

**Иярченле кушма җөмлә.** Иярченле кушма җөмлә турында төшенчә. Иярченле кушма җөмләнең төзелеше ягыннан төрләре: синтетик һәм аналитик. Синтетик иярчен җөмләлр янында тыныш билгеләре. Аналитик иярчен җөмләләр янында тыныш билгеләре.

Иярченле кушма җөмләләрнең мәгънә ягыннан төрләре. Иярчен ия һәм иярчен хәбәр җөмлә. Иярчен тәмамлык һәм иярчен аергыч җөмлә. Иярчен урын һәм иярчен вакыт җөмлә. Иярчен рәвеш һәм иярчен күләм җөмлә.

Иярчен шарт һәм иярчен кире җөмлә. Кушма җөмләләрнең синонимлыгы.

**Катлаулы төзелмәләр.** Катлаулы төзелмәләр турында төшенчә: катлаулы кушма җөмлә, тезем.

Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә һәм аның төрләре. Тиңдәш иярүле күп иярченле кушма җөмлә. Тиңдәш түгел иярүле күп иярченле кушма җөмлә. Бер-бер артлы иярүле күп иярченле кушма җөмлә. Берничә төр иярүле күп иярченле кушма җөмлә.

**Катнаш кушма җөмлә. Тезем.**

Кушма һәм катлаулы җөмләләргә анализ ясау тәртибе.

**1.7. ПУНКТУАЦИЯ**

**Пунктуация** турында гомуми төшенчә.

Җөмләнең мәгънәсе һәм төзелеше, интонация һәм тыныш билгеләре. Нокта, сорау һәм өндәү билгеләре. Күп ноктлар һәм куштырнаклар куела торган очраклар. Өтер, нокталы өтер, ике нокта куела торган очраклар.

Сызык һәм җәяләр куела торган очраклар.

Җөмләдәге тыныш билгеләренә пунктацион анализ.

**Стилистика һәм сөйләм культурасы.** Әдәби тел һәм аның стильләре. Язма һәм сөйләмә стиль. **Функциональ стильләр**: матур әдәбият стиле һәм аның лексик, грамматик үзенчәлекләре; вакытлы матбугат стиле һәм аның үзенчәлекләре; фәнни стиль һәм аны үстерү өчен кирәкле шартлар; эш кәгазъләренә хас үзенчәлекләр; эпистоляр стиль һәм аның телебез тарихында тоткан урыны.

Сөйләмдә синонимнарны куллану. Грамматик синонимнар һәм аларның төрләре: морфологик һәм синтаксик синонимнар. Морфологик синонимнарны сөйләмдә куллану үзенчәлекләре. Синтаксик синонимнарның үз эчендәге төрләре: сүзтезмәләрнең синонимлыгы, җөмлә кисәкләрен синонимик куллану, бер һәм ике составлы җөмләләрнең синонимлыгы, фигыль юнәлешләре белән бәйле синонимлык (актив һәм пассив төзелмәләр синонимлыгы), туры һәм кыек сөйләм синонимлыгы. Аналитик һәм синтетик иярчен җөмләләр синонимлыгы, иярчен кисәк һәм иярчен җөмлә синонимлыгы, тезмә кушма җөмләләрне синонимик куллану.

**Синтаксик калькалар** һәм аларны сөйләмдә куллану.

**Сөйләм культурасы** һәм аның нигезләре. Сөйләмгә куела торган таләпләр: 1) сөйләм төгәл булсын; 2) сөйләм аңлаешлы булсын; 3) сөйләм саф булсын; 4) сөйләм җыйнак булсын; 5) сөйләм әһәңле булсын.

## РАЗДЕЛ 4. ӘДӘБИЯТ ТЕОРИЯСЕ (ТЕОРИЯ ЛИТЕРАТУРЫ)

Сүз сәнгате буларак әдәбият. Язма әдәбият һәм фольклор. Халык авыз иҗаты жанрлары. Әдәби төрләр һәм жанрлар. Образлар системасы. Автор образы, хикәяләүче образы; лирик герой.

Әдәби әсәрнең формасы һәм эчтәлеге: тема, проблема, идея, сюжет, композиция; сюжет элементлары; конфликт. Әдәби әсәрнең теле. Әдәби сурәтләү чаралары: чагыштыру, эпитет, метафора, гипербола, метонимия, символ, аллегория, җанландыру. Пейзаж. Портрет. Юмор һәм сатира.

Шигырь төзелеше: ритм, рифма, строфа.

Әдәбият тарихы. Әдәби процесс. Әдәби юнәлешләр һәм агымнар.

Матур әдәбиятта гомумкешелек кыйммәтләре һәм әсәрнең милли үзенчәлеге.

Тормышны танып белүнең бер формасы һәм кеше рухи дөньясының байлыгын, күптөрлелеген чагылдыручы буларак матур әдәбият.

Әдәбиятның формалашуы, шартлары, сәбәпләре. Әдәбиятны чорларга бүлүнең закончалыклары. Әдәбиятның үсешендә тотрыклы сыйфатлар – традицияләр саклау; үсеш – яңарыш, новаторлык. Әдәбиятны алга үстерүче сәбәпләр.

**Татар халык авыз иҗаты**

Халыкның милли рухи культура хәзинәсе буларак халык авыз иҗаты. Фольклор әсәрләрендә гомумкешелек кыйммәтләрнең зур урын тотуы. Халык иҗатының язма әдәбият үсешенә, әдәби телгә зур йогынты ясавы. Фольклорның төп жанрлары: әкиятләр, мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар, җырлар, бәетләр, риваятьләр һәм легендалар, дастаннар.

***Халык әкиятләре.*** «Өч кыз», «Зөһрә кыз», «Камыр батыр», «Ак бүре», «Таң батыр», «Кәҗә белән сарык». ***Бәетләр.*** «Сак-Сок». ***Риваятьләр һәм легендалар.*** «Иске Казан каласы корылуы», «Шәһәр ни өчен Казан дип аталган», «Елан тавы» риваятьләре; «Зөһрә кыз», «Кеше гомере ничек корылган» легендалары. ***Халык җырлары.*** «Иске кара урман», «Гөлҗамал». Кыска җырлар. ***Мәзәкләр.*** Хуҗа Насретдин турындагы мәзәкләр. ***Мифлар.*** «Су иясе», «Алып кешеләр». ***Дастаннар.*** «Идегәй» дастаны.

## РАЗДЕЛ 5. ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНЫҢ ТАРИХЫ (ИСТОРИЯ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ)

**Борынгы һәм урта гасыр татар әдәбияты.** Борынгы һәм урта гасыр әдәбиятының мифологиягә һәм халык авыз иҗатына нигезләнүе. Әдәбиятта дини-әхлакый, суфыйчыл һәм дөньяви карашларның үрелеп баруы.

Бу чорлар әдәбиятында төп тема һәм мотивлар (гуманлылык, әхлакый сафлык, мәхәббәт, кешенең бәхеткә хокукы, сабырлык, изгелек). Сүз сәнгатенең ислам дине идеологиясенә нигезләнүе. Үзәктә Алла һәм Кеше мөнәсәбәте тору.

***Гомумтөрки әдәбият.*** Орхон-Енисей ташъязмалары. Кол Гали.

«Кыйссаи-Йосыф» поэмасы.

***Алтын Урда чоры әдәбияты***. С. Сараи «Сөһәйл вә Гөлдерсен», «Гөлестан бит төрки» поэмасы. Котб. «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы.

***Казан ханлыгы чоры әдәбияты***. Кол Шәриф шигырьләре. «Күңел», «Баш күтәр гафтдин». Мөхәммәдьяр. «Нуры содур» поэмасы.

***XVI-XVIII гасыр татар әдәбияты***. М. Колый. Хикмәтләр: «Юмартлык бу күңелне рушан кылыр...», «Игенчелек гали эшдер...», «Гыйлемлек хак рәхәттер...».

Г.У. Имәни. «Мөһиммәтез – заман» поэмасыннан «Йегет булмакның бәяны» бүлеге.

**XIX йөз татар әдәбияты.** Әдәбиятның мәгърифәтчелек идеяләрен нигез итеп алуы. Мәгърифәтчелек чоры әдәбиятының үзенчәлекләре. Әдәбиятның чынбарлык проблемаларына мөрәҗәгать итүе. Яңа заман сүз сәнгатенә нигез салыну. Әдәбиятның мәгариф һәм мәдәният үсеше белән бәйләнеше. Яңа төрләр һәм жанрлар барлыкка килү. Дөньяви проблемаларның дини карашлар белән кушылып китүе. Жанрлар үсеше, иҗат методларының (юнәлешләренең) ачыклана баруы. Прозаның мөстәкыйль төр булып формалашуы. Драматургиянең беренче үрнәкләре.

***Яңарыш чоры әдәбияты.*** Г. Кандалый шигырьләре. «Иген икмәк бирер икмәк», «Йакутлар табыладыр вакыт берлән...», «Бу илләрдә торып калсам...» шигырьләре, «Сәхибҗамал» поэмасы. К. Насыйри. «Әбүгалисина» повесте. М. Акъегет. «Хисаметдин менла» повесте. Р. Фәхретдин. «Әсма, яки Гамәл вә җәза» повесте (өзекләр). Акмулла шигырьләре: «Башка милләт алга таба барыр булды...», «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән». «Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе» поэмасыннан өзек. Ф. Кәрими. «Морза кызы Фатыйма» повесте. З. Бигиев. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы. Ф. Халиди. «Рәдде Бичара кыз» драмасы.

**XX гасыр башы татар әдәбияты.** Татар әдәбиятының Яңарыш чорына керүе. Милли азатлык хәрәкәте, 1905-1907 еллар инкыйлабы тудырган шартларда матбугат, әдәбият һәм сәнгатьнең күтәрелеше; драматургиянең, татар театрының үсүе; яңа жанр һәм стильләр. Чынбарлыкны реалистик һәм романтик сурәтләү алымнары ярдәмендә чагылдыру. Яңа әдәби агымнар эзләү.

Татар сүз сәнгатенең Шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы. Әдәбиятнең реалистик һәм романтик чагылдыру үзенчәлекләре. Әхлакый һәм фәлсәфи эзләнүләр.

Ф. Әмирхан. «Хәят», «Фәтхулла хәзрәт» повестьлары. «Бер хәрабәдә», «Шәфигулла агай» хикәяләре.

Г. Ибраһимов хикәяләре. «Яз башы». «Яшь йөрәкләр» романы. «Татар шагыйрьләре» китабы.

Г. Исхакый. «Сөннәтче бабай», «Кәҗүл читек» хикәяләре. «Көз», «Остазбикә», «Ул әле өйләнмәгән иде» повестьлары. «Алдым-бирдем» комедиясе.

Г. Камал «Беренче театр», «Банкрот» комедияләре.

Ш. Камал «Буранда» хикәясе. «Акчарлаклар» повесте.

Дәрдемәнд шигырьләре. «Каләмгә хитап», «Кораб», «Гөрләгән сулар башында», «Бүзләрем маналмадым», «Без».

С. Рәмиев шигырьләре. «Таң вакыты», «Сызла, күңелем», «Авыл», «Пәйгамбәр» әсәрләре.

Г. Тукай шигырьләре. «И каләм!», «Туган авыл», «Пар ат», «Туган җиремә», «Милли моңнар», «Кичке азан», «Ана догасы», «Шагыйрь», «Өзелгән өмид», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәрләре.

М. Гафури. «Сарыкны кем ашаган?» мәсәле.

М. Фәйзи драмалары. «Галиябану», «Ак калфак».

Г.Колахмәтов. «Ике фикер» драмасы.

**XX гасыр татар әдәбияты.** Тарихи-иҗтимагый, мәдәни вакыйгалар (инкыйлаблар, гражданнар сугышы, күмәк хуҗалыклар төзү, репрессияләр, ике тапкыр алфавит алышыну) һәм аларның әдәбиятка йогынтысы. 20-30 нчы елларда әдәбиятның каршылыклы үсеше. Вульгар социологизм күренеше. Төп иҗат методы буларак социалистик реализмның кабул ителүе. Бөек Ватан сугышы һәм аның әдәбиятта чагылышы. Илленче еллар ахырыннан башлап әдәбиятта сыйфат үзгәрешләре башлануы. «Хрущев җепшеклеге»нең сүз сәнгатенә уңай йогынтысы. Сәнгати эзләнүләрнең киңәюенә, тема-мотивларның, жанрларның төрлелегенә омтылу. Совет чоры татар әдәбиятының каршылыклы үсеше. Төп тема-проблемалар. Әдип һәм җәмгыять мөнәсәбәте. Сүз сәнгатендә милләт проблемасының алгы планга чыгуы. Әдипләрнең заман сорауларына актив мөрәҗәгать итүе. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең әдәбиятта чагылышы.

Совет чоры әдәбиятында революцион вакыйгаларның әдәбиятка йогынтысы һәм әдәбиятта чагылышы. Традицияләрнең яңаруы, яңа җәмгыять сыйфатларын эзләү, яңа герой образы. Ватан, ил, халык образларның эпик гәүдәләнешн; шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре, гражданлык хисе, халыклар язмышы, кешенең рухи дөньясы, чор кыйммәтләре турында уйлану. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы. Дөнья әдәбияты белән бәйләнеш, бүгенге көн әдәбиятында яңарыш.

***1920-30 еллар.*** Ф. Бурнаш. «Таһир-Зөһрә» шигъри трагедиясе.

Г. Ибраһимов. «Алмачуар» хикәясе. «Кызыл чәчәкләр» повесте.

Г. Кутуй. «Тапшырылмаган хатлар» повесте.

Һ. Такташ шигырьләре. «Зәңгәр күзләр», «Алсу»,«Мокамай». «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы. «Җир уллары» трагедиясе.

М. Галәү. «Болганчык еллар» романы.

К. Тинчурин. «Американ» комедиясе. «Сүнгән йолдызлар» драмасы.

Г. Рәхим. «Идел» повесте.

Г. Исхакый. «Җан Баевич» комедиясе.

***Ватан сугышы чоры әдәбияты.*** Г. Кутуй. «Сагыну» нәсере.

Ф. Кәрим шигырьләре: «Үлем уены», «Кыр казы», «Сибәли дә сибәли», «Сөйләр сүзләр бик күп алар».

М. Җәлил шигырьләре. «Җырларым», «Тик булса иде ирек», «Кызыл ромашка». «Сандугач һәм чишмә» балладасы. «Моабит дәфтәрләре» циклы.

Ә. Еники. «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә» хикәяләре.

Ф. Хөсни «Йөзек кашы» повесте.

***Сугыштан соңгы чор әдәбияты.*** Х. Туфан шигырьләре. «Гөлләр инде яфрак яралар», «Киек казлар», «Чәчәкләр китерегез Тукайга», «Кайсыгызның кулы җылы», «Агыла да болыт агыла».

Х. Вахит. «Беренче мәхәббәт» драмасы.

***1960-1980 еллар әдәбияты.*** С. Хәким шигырьләре. «Әнкәй», «Һәйкәл урынында уйланулар», «Колын», «Башка берни дә кирәкми», «Сусау».

Ә. Еники. «Әйтелмәгән васыять», «Кем җырлады?», «Туган туфрак», «Матурлык» хикәяләре.

А. Гыйләҗев. «Өч аршын җир» повесте.

Ш. Хөсәенов. «Әни килде» драмасы.

***Хәзерге әдәбият.*** Ф.Яруллин. «Җилкәннәр җилдә сынала» повесте, «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» шигыре.

М. Әгъләмов шигырьләре. «Китә алмыйм...», «Учак урыннары», «Каеннар булсаң иде».

А. Гыйләҗев. «Җомга көн кич белән» повесте.

М. Мәһдиев. «Кеше китә – җыры кала» повесте.

Т. Миңнуллин. «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасы.

Н. Фәттах. «Ител суы ака торур» романы.

И. Юзеев. «Бакчачы турында баллада» балладасы. Шигырьләре. «Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасы. «Гашыйклар тавы» поэмасы.

Ф. Садриев. «Таң җиле» романы.

И. Салахов. «Колыма хикәяләре» романы.

Ф. Бәйрәмова. «Болын» повесте.

М. Хәбибуллин. «Кубрат хан» романы.

Т. Миңнуллин. «Эзләдем, бәгърем, сине» драмасы.

Р. Фәйзуллин. «Нюанслар илендә» циклы.

Зөлфәт шигырьләре. «Баш очында...», «Дүрт җыр», «Тамыр көлләре», «Тойгыларда алтын яфрак шавы».

М. Кәбиров. «Мәхәббәттән җырлар кала» повесте. Р. Зәйдулла шигырьләре: «Без очарга әзерләнгән идек...», «Соңару», «Буран».

**Башкортстандагы татар әдәбияты.**

Төбәкчелек әдәбияты турында төшенчә. Башкортстан төбәгенең татар әдәбияты тарихында тоткан урыны. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында Башкортстандагы татар әдәбиятының үсеш тенденцияләре, төп иҗат мотивлары, жанр үзенчәлекләре. Поэзия (Ә. Атнабаев, С. Рәхмәтулла, М. Кәбиров, Р. Идиатуллин, Ф. Габдрахимов, М. Нәзиров, Х. Мөдәрисова, М. Вафин, Д. Булгакова, Л. Сәгыйдуллина, И. Фазлетдинов, А. Хәлиуллина, Р. Сөләйманов һ.б), проза (Т. Таһиров, С. Поварисов, Кәрим Кара, М. Кәбиров, Д. Булгакова, Д. Булатова һ.б.).

Югары уку йортларының татар теле һәм әдәбияты бүлекләренә укырга керүчеләргә тәкъдим ителгән татар теле һәм әдәбияты программасы мәктәп программасын тулысынча үз эченә ала һәм гомуми белем бирү стандартларына нигезләнә. Бу программалар нигезендә абитуриентларның белеменә мәҗбүри минимум күләмдә таләплар куела.

**Татар теленнән абитуриентларга белеменә кайбер таләпләр:**

телне тулы бер система буларак күзаллый белергә;

татар халкының этник төркемнәре һәм диалектлары, төрки телләр, татар теле, татар язуы, татар халкының рухи, әхлакый, мәдәни мирасын барлый белергә;

татар телен иҗтимагый күренеш буларак аңлау, тел нормаларын саклап, тормышның төрле ситуацияләренә бәйле рәвештә тел чараларын дөрес кулланып, аралаша-аңлаша белергә;

тел берәмлекләрен танып, аларны тикшерә, чагыштыра алу һәм аралашуда урынлы куллана алырга;

татар әдәби тел нормаларын һәм стилистик мөмкинлекләрен ачык күзаллый белергә тиеш.

**Татар әдәбиятыннан абитуриентларның белем дәрәҗәсенә кайбер таләпләр:**

укырга керүчеләрнең татар әдәбияты буенча сынауга әзерлегенә, белем дәрәҗәсенә таләпләр:

татар әдәбиятындагы аерым язучылар иҗаты, әсәрләр хакында гомуми күзалларга;

әдәби-тарихи процессның төп закончалыкларын, этапларын, чор әдәбиятына зур өлеш керткән әдипләр иҗатын белергә;

әдәбият тарихы һәм теориясе буенча белемнәргә (тема, проблема, идея, пафос, образлар системасы, сюжет-композиция, телнең сәнгати сурәтләү чаралары, әдәби деталь) нигезләнеп, әдәби әсәрне анализларга һәм шәрехләргә;

әсәрне чорга хас әдәби юнәлеш белән бәйлелектә тикшерергә, аңлатырга;

классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белергә;

әдәбият теориясенә караган иң әһәмиятле төшенчәләрне, аларның билгеләмәләрен белергә (әдәби процесс, иҗат методы, сәнгатьчә алымнар чаралар, анализ төрләре, язучының стиле, әдәбият һәм чор, шәхес һәм җәмгыять бәйләнешләре);

әдәби төрләр һәм жанрлар, шигырь төзелеше, тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре хакында белергә;

татар әдәбиятында традицияләр һәм яңару процессы, жанрлар үсеше турында гомуми күзаллау булырга;

әдәби әсәрнең әһәмиятен, кыйммәтен, үзенчәлекләрен аңлый һәм дәлилле итеп аңлата, исбатлый белергә тиеш.

## 3. Методические рекомендации

При выполнении заданий теста рекомендуется сначала просмотреть задания и выполнять их последовательно. Если ответ вызывает затруднения, продолжайте выполнять тест, отвечая на следующие вопросы, затем вернитесь к ответу на пропущенные задания.

Необходимо рассчитать время выполнения теста таким образом, чтобы ответить на все вопросы и оставить несколько минут для проверки своих ответов в конце отведенного на тест времени.

**При сдаче экзамена в тестовой форме в дистанционном формате** необходимо придерживаться содержания и требований этой же предложенной программы по татарскому языку и литературе, поскольку эта программа составлена с учетом объема и содержания ФГОС среднего общего образования РФ. Экзамен в тестовой форме проходит в фоме выбора только одного верного ответа из предложенных вариантов ответа. Понятно, что предоложенные тесты не могут полностью охватить весь объем программы, так как их количество ограничено 30 тестовыми вопросами.

Татар теле һәм әдәбияты буенча сынау югарыда бирелгән программалар нигезендә уку йорты тарафыннан мөстәкыйль төзелгән һәм түбәндә үрнәк итеп тәкъдим ителгән тест сорауларына җавап бирү рәвешендә уздырыла. Ләкин тестларның сорауларының күләме чикләнгәнлектән, аңлашыла ки, бу программаларның эчтәлеген алар тулысынча яктыртып бетерә алмый. Чөнки тестлар барлыгы ике вариантта булып, абитурианетлар аларның берсенә генә җавап бирә. Тестлар 30 сорауны (15 сорау тел буенча, 15 сорау әдәбият буенча) үз эченә алып, абитуриентлар һәр сорауның 4 тәкъдим ителгән җавабының берсен генә дөрес дип күрсәтә ала. По каждому предложенными вопросу имеется 4 варианта ответа и абитуриент может выбрать только один правильный на его взгляд ответ. Ниже предлагается образцы тестов для тренировки ответа.

**3.1. Образцы тестов для проверки знаний и умений.**
**Күнекмәләр һәм белемне тикшереп карау өчен үрнәк тестлар.**

**1. Кайсы авазларны әйткәндә иреннәр актив катнаша?**
1) *б, п, м, w*
2) *н, м*
3) *о, у, ө, ү*
4*) в, ф*}

**2. *Ь* хәрефе куелган сүзләр рәте:**
1) *тәк…дим, мәнфәгат…, роял…*
2) *дөн…я, иг…тибар, дәр…я*
3) *сәгат…, шигыр…, мик…дар*
4) *гам..., бәгыр…, тәнкыйт…*}

**3. Кайсы сүздә яңгырау аваз саңгыраулаша?**
1) *иҗтимагый*
2) *унбер*
3) *борынгы*
4) *дәрәҗәле*}

**4. Тамыр ул –**
1) төп лексик мәгънәне белдергән мәгънәви кисәк

2) лексик-грамматик мәгънә белдергән кисәк
3) саф грамматик мәгънә белдергән кисәк
4) аның мәгънәсе юк}

**5.** *Китапларыңа* **сүзендә ничә мәгънәви кисәк бар?**
1) дүрт
2) ике
3) өч
4) биш}

**6.** ***Чуар тавык –***
1) сүзтезмә
2) тезмә сүз
3) фразеологик әйтелмә
4) кушма нигез}

**7.** *Битлек, башлык, авызлык, күзлек, борынлык* **сүзләрендә**
1) ясаучы нигез белдергән әгъза өчен билгеләнгән җайланманы белдерә
2) ясаучы нигез белдергән хуҗалык кирәк-яраклары яки төзү эшләре өчен кирәк булган материалны белдерә
3) ясаучы нигез белдергән әйбернең саклану яки ташлану урынын белдерә
4) ясаучы нигез белдергән предметларның күп үскән яки күп булган урынны белдерә}

**8. Сыйфат ачыклап килгән сүз ничек атала?**
1) сыйфатламыш
2) аергыч
3) исем
4) аныклагыч}

**9. Билгеләү алмашлыгы булмаган җавапны күрсәтергә**
1) *бары*
2) *һәммә*
3) *үз*
4) *теге*}

**10.** *Җылы сөяк сындырмый, салкын җанны тындырмый* **җөмләсендә ия**
1) *җылы, салкын* сүзләре
2) *салкын* сүзе
3) *сөяк, салкын* сүзләре
4) *сөяк* сүзе}

**11. Төп мәгънәләре охшаш булган сүзләр ничек атала?**

1) эпитетлар

2) синонимнар

3) парлы сүзләр

4) метафоралар}

**12. Лексикология фәнендә географик атамаларны өйрәнә торган бүлек ничек атала?**

1) антропонимика

2) зоонимика

3)топонимика

4) арнитология}

**13. Бирелгән җөмләдә аерымланган хәлнең кайсы төре?**

*Мин ярама яптым ул яулыкны, басар өчен агышын канымның* (М. Җәлил)

1) аерымланган максат хәле

2) аерымланган сәбәп хәле

3) аерымланган рәвеш хәле

4) аерымланган шарт хәле}

**14. Синтетик бәйләү чараларыннан гына торган тезмәне табарга**

1) әмма, өчен, шуны

2) янәшә тору, *...-ган чакта*, *кебек*

3) килеш кушымчалары, *...-га күрә*, *һәм*

*~кайда, шул сәбәпле, -дай/-дәй* кушымчалары}

**15. Гади җөмләне табыгыз**

1) *Хатын да уңайсызлануын яшерә алмыйча, кулындагы базар сумкасын бер кулыннан икенчесенә күчерә иде*

2) *Пароход инде күптән узып киткән, болытлар белән күк йөзе тукталып калган, тик Шәфика гына башының җиңелчә әйләнү рәхәтеннән баскан җирендә тик тора*

3) *Көтелмәгән бер вакыйга булды: һич уйламаганда, Бәдрия карчык килеп төште*

4) *Хәсәнбай ничектер үзгәргән, бу инде ул яшәгән, ул сагынган авыл түгелдер кебек иде}*

**16. Борынгы татар әдәбиятына хас булган сыйфатлар**

1) дин, суфыйчылык карашларын алга сөрү, гадел хөкемдарны гәүдәләндерү

2) миллилек, халыкчанлык сыйфатларын үстерү

3) мәгърифәт, прогрессны пропагандалау

4) партиялелек, сыйнфыйлык, патриотизм, интернациональлек идеяләрен культ итү}

**17. Дастанга хас сыйфатлар?**

1) икеьюллык строфалардан – бәетләрдән төзелә, рифмалардан соң рәдиф кабатланып килә, уртача күләме 5-12 строфадан тора, ахырында автор үзенең исемен яки кушаматын куллана.

2) башта 3 юлы үзара рифмалашкан, дүртенче юлы рифмасыз дүртьюллыклар, һәр строфа имди сүзенә тәгәлләнә

3) мәхәббәт тарихын сөйләгән эпик әсәр

4) лиро-эпик характердагы әдәби әсәр. Анда вакыйга-хәлләр уй-кичерешләр белән үрелеп бара. Кагыйдә буларак әкияти сюжетлар, легенда-риваятьләр эшкәртелә, хыялый һәм чынбарлык күренешләре үзара үрелеп бара}

**18. Кол Гали язган әсәр**

1) “Кыйссаи Йосыф”

2) “Хөсрәү вә Ширин”

3) “Кыйссасел-әнбия”

4) “Кодатгу белек”}

**19. Борынгы чорда түбәндәге язу (алфавитлар) кулланылган. Кайсы алфавит булмаган?**

1) рун язуы

2) уйгур

3) миф язуы

4) дөрес җавап юк}

**20. Г. Тукайныкы булган әсәрләр тезмәсен билгеләгез**

1) «Таныш моңнар», «Үтеп барышлый», «Ап-ак карга ятып бер елыйсы килә...»

2) «Кайсыгызның кулы җылы?», «Агыла да болыт агыла», «Ак каен»

3) «Көзге җилләр», «Милли моңнар», «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш»

4) «Вәхшәт», «Кызыл ромашка», «Ана бәйрәме»}

**21. Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» музыкаль драмасында әти-әнисе Галиябануны кемгә кияүгә бирергә җыеналар?**

1) Исмәгыйльгә

2) старостага

3) Хәлилгә

4) күрше малаена}

**22. XX йөз башы язучылары**

1) М. Җәлил, Ф. Кәрим, Н. Арсланов, Г. Афзал

2) Ш. Камал, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый

3) Г. Гыйльманов, М. Кәбиров, М. Галиев, Ә. Баянов

4) Г. Кандалый, Г. Сәмитова, Кол Гали, Кол Шәриф}

**23. Хикәя – ул**

1) бер яки берничә вакыйганы эченә алган, кеше характерының бер сыйфаты, үсү-үзгәрүе хакында сөйләүче эпик жанр

2) көлкеле ситуациягә корылган, көлкеле конфликтка нигезләнгән жанр

3) сюжет сызыклары хис-кичереш белән үрелеп бара торган лиро-эпик жанр

4) чәчмә (эпик) формада хис-кичерешнең үсешүзгәрешен күрсәтә торган лиро-эпик жанр}

**24. Һ.Такташның «Мокамай» әсәрендәге геройның чын исеме**

1) Мөхәммәтҗан

2) Мөхәммәтзакир

3) Мөхәммәтгазиз

~Мөхәммәтшәриф}

**25. Г.Исхакыйның «Җан Баевич» әсәренең жанры**

1) комедия

2) драма

3) трагедия

4) әкият}

**26. Ш.Камалның «Буранда» әсәрендә кайсы герой әнисе янына кайтырга ашкына?**

1) Хөсәен

2) Мостафа

3) Гайшә

4) Йосыф}

**27. Габдулла Тукай кайчан туган**

1) 1906 елның 15 феврале

2) 1921 елның 23 мае

3) 1937 елның 26 апреле

4) 1886 елның 26 апреле}

**28. М. Фәйзинең “Галиябану” әсәрендә Бәдри кем ул?**

1) абыйсы

2) этисе

3) энесе
~яратып йөргән кешесе}

**29. Һ. Такташның “Мәхәббәт тәүбәсе” поэмасында төп геройларның берсе**

1) Алсу
2) Зөбәйдә
3) Хәят
4) Сәлимә}

**30. “Рөстәм маҗаралары” исемле “хыялый”романны кем язган?**

1) Г. Кутуй
2) Һ. Такташ
3) Х. Туфан
4) Ф. Әмирхан}

Тикшерү өчен тестлардагы сорауларга дөрес җаваплар;

1. – 1; 2. – 4; 3. – 1; 4. – 1; 5. – 1; 6. – 1; 7. – 1; 8. – 1; 9. – 4; 10. – 1; 11. – 2; 12. – 3; 13. – 2; 14. – 2; 15. – 1; 16. – 1; 17. – 4; 18. – 1; 19. – 3; 20. – 3; 21. – 1; 22. – 2; 23. – 1; 24. – 1; 25. – 1; 26. – 2; 27. 4; 28. 2; 29. – 2; 30. 1.

МАКСИМАЛЬНЫЙ БАЛЛ 100
Соответствие баллов и оценок:
«отлично» – от 91 до 100 баллов
«хорошо» – от 71 до 90 баллов
«удовлетворительно» – от 51 до 70 баллов
«неудовлетворительно» – от 0 до 50 баллов

## 3.3. РЕКОМЕНДУЕМАЯ ЛИТЕРАТУРА
## ТӘКЪДИМ ИТЕЛГӘН ӘДӘБИЯТ

**Татарский язык**

**Татар теле**

1. Абдуллина Р.С. Хәзерге татар теленең орфографиясе һәм орфоэпиясе. – Казан: Мәгариф, 2009. – 239 б.

2. Галимов И.Р**.** Мавыктыргыч лексикология: Татар урта гомуми белем мәктәпләре, педагогия колледжлары һәм училищелары өчен уку ярдәмлеге. – Казан: Мәгариф, 2001. – 135 б.

159. Максимов Н.В. Татар теленнән тестлар. – Казан: Мәгариф, 2002. – 159 б.

7. Сәлимов Х.Х. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. – Казан: Татар.кит. нәшр., 2005. – 143 б.

8. Татар телендә тыныш билгеләре. – Казан: Мәгариф, 2009. – 48 б.

10. Татар теленнән кагыйдәләр җыентыгы / Төз.автор Гыймадиева Р.В. – Казан: Нәшрият йорты, 2005. – 48 б.

10. Тел – белемнең ачкычы. Татар теле һәм сөйләм үстерү дәресләре:

12. Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М. Татар теленнән күнегүләр һәм тестлар. – Казан: Яңалиф, 2006. - 184 б.

207. Харисова Ч.М. Татар теле. Теория, күнегүләр, тестлар: Абитуриентлар һәм студентлар өчен ярдәмлек. – Казан: Мәгариф, 2006. – 207 б.

15. Харисова Ч.М. Татарский язык: справочник. – Казань: Магариф, 2009. – 199 с.

16. Харисова Ч.М., Харисов Ф.Ф. Татар теле: олимпиадага әзерләнү. 10 нчы сыйныф (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2016. – 87 б.

17. Харисова Ч.М., Харисов Ф.Ф. Татар теле: олимпиадага әзерләнү. 9 нчы сыйныф (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). — Казан: Мәгариф-Вакыт, 2016. – 87 б.

18. Харисова Ч.М., Харисов Ф.Ф. Татар теле: олимпиадага әзерләнү. 11 нче сыйныф (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). – Казан: Мәгариф-Вакыт, 2016. — 87 б.

19. Шәмсетдинова Р.Р. Татар теле: Күнегүләр. Анализ үрнәкләре. Тестлар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2007. – 192 б.

20. Гареева Р.Р., Мукимова Н.А., Насипов И.С. Башкортстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларының 5-9 нчы сыйныф укытучылары өчен «Татар теле» укыту предметы буенча белем бирү үрнәк программалары. Уфа: Китап, 2019. – 56 с.

21. Хабибов Л.Г., Гафурова Ф.А., Рәхимов Ф.Ф. Татар теле: Башкортстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларының 5 нчы сыйныфы өчен уку кулланмасы. Уфа: Китап, 2019. – 192 с.

22. Миңнеәхмәтов Р.Р., Миңнеәхмәтова Т.Ф. Татар теле: Башкортстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларының 6 нчы сыйныфы өчен уку кулланмасы. Уфа: Китап, 2019. – 288 с.

23. Хәбибов Л.Г., Алчина Н.М. Татар теле: Башкортстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларының 7 нче сыйныфы өчен уку кулланмасы. Уфа: Китап, 2019. – 204 с.

24. Гыйззәтуллин И.С., Баһрамшина Т.Г., Фәттәхова Л.Н. Татар теле: Башкортстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларының 8 нче сыйныфы өчен уку кулланмасы. Уфа: Китап, 2019. – 172 с.

25. Насипов И.С. Вагапов Н.Х., Ахунова И.Г. Татар теле: Башкортстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларының 9 нчы сыйныфы өчен уку кулланмасы. Уфа: Китап, 2019. – 236 с.

**Татарская литература**

**Татар әдәбияты**

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2011.– 231 б.

2. Ганиева Ф. А., Абдуллина Д. М., Рамазанова Ч. Р. Әдәбият. Урта гомуми белем мәкт. 10 нчы с-фы өчен д-лек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 239 б.

3. Закирҗанов А. М., Фәхретдинова Г.М. Әдәбият. Урта гомуми белем мәкт. 9 нчы с-фы өчен д-лек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 255 б.

4. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф. Заһидуллина, Ә.М. Закирҗанов, Т.Ш. Гыйләҗев, Н.М. Йосыпова.– Тулыл. 3 нче басма.– Казан: Мәгариф, 2012.– 319 б.

6. Хәлиуллина А.Г., Сөләйманова Д.Д. Туган як әдипләре. Башкортстанда хәзерге татар прозасы: шәхес, иҗат, тәнкыйть. Уку басмасы. – Уфа: Китап, 2013. – 320 б.

7. Хәсәнова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я. Татар әдәбияты. Һәр дәрескә тестлар. Казан: Мәгариф-Вакыт, 2016. – 88 б.

7. Хәсәнова Ф.Ф., Сафиуллина Г.М., Гарифуллина М.Я. Татар әдәбияты. 9 с-ф өчен д-лек. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2016. – 255 б.

8. Хәсәнов М.Х., Әхмәдуллин А.Г., Галимуллин Ф.Г., Нуруллин И.З. Әдәбият (XX йөз башы һәм 20 нче еллар): Татар урта гомуми белем мәкт. 10 нчы с-фы өчен д-лек / А.Г. Әхмәдуллин редакциясендә. – 3 нче басма. – Казан: Мәгариф, 2005. – 399 б.

9. Әхмәдуллин А.Г., Галимуллин Т.Н. һ.б. Әдәбият (XX йөзнең 30-90 нчы елларда татар әдәбияты): Татар урта гомуми белем мәкт. 11 нче с-фы өчен д-лек. – Казан: Мәгариф, 2000. – 335 б.

10. Габидуллина Ф.И., Закирҗанов Ә.М. Татар әдәбиятыннан олимпиадага әзерләнәбез (укытучылар һәм укучылар өчен ярдәмлек). – Казан: Отечество, 2023. – 148 б.

**Интернет ресурсыт / Интернет ресурслар**
https://tatkniga.ru/
http://www.antat.ru/ru/tatzet/
http://www.tatknigafund.ru/
http://kitap.net.ru/
http://shigriyat.ru/
http://adiplar.narod.ru/
http://www.peoples.org.ru/tatar.html
http://tt.wikipedia.org/wiki/Татар_теле
http://www.tugan-tel.com/
http://tatardeti.blogspot.ru/p/blog-page_6123.html
http://www.webkitap.ru/
http://anatele.ef.com/partner/anat/default.aspx
http://tatar.com.ru/
https://www.antat.ru/ru/tatzet/
https://antat.ru/ru/iyli/publishing/book/uchebniki/
https://www.antat.ru/ru/iyli/publishing/book/index.php

Составитель программы: зав.кафедрой татарского языка и литературы БГПУ им. М.Акмуллы, кандидат филологических наук, доцент Н.У.Халиуллина